**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“24” ноябрь 2025 ел. № 2

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);
- Авыл территориясен төзекләндерү (үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту,хезмәтләр өчен түләү);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, вак таш сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау (зират территориясен чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И.